ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 533-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 533-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2394-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш, № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «дотацияләрнең» сүзеннән соң «(җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә;

2) 3 пунктта «дотацияләрнең» сүзеннән соң «(җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә;

3) 4 пунктның беренче абзацында «дотацияләрнең» сүзеннән соң «(җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә;

4) 4[1] пунктта:

а) беренче абзацта «дотацияләр» сүзеннән соң «(җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктчада «дотацияләр» сүзеннән соң «(җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә;

5) 5 пунктның бишенче абзацында «дотацияләр» сүзеннән соң «(җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә;

6) 6 пунктта «бюджетларыннан дотацияләр» сүзләреннән соң «(җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы нигезләмәләрен (әлеге Закон редакциясендә) исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Бюджет кодексының 136 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 февралендәге 36-ФЗ номерлы Федераль закон белән җирле бюджетларга дотация бирү дәрәҗәсен билгеләгәндә исәпкә алына торган керемнәр составыннан җирле бюджетларга муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы күрсәткечләренә, шул исәптән, социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне бүләкләү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге иң яхшы тәҗрибәләр өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләр төшереп калдырыла.

Шуңа бәйле рәвештә әлеге закон проекты белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын җайга сала торган шундый ук үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчен югалтуын тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре кимүгә китерми һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.